
**Тупны җибәрмә!**

Балалар, бер-берсенә кул сузарлык ара калдырып, түгәрәккә тезеләләр дә кулларын артка куеп, җилкә киңлегендә аякларын аерып басалар. Әйдәүче түгәрәк уртасына керә һәм тупны кайсы да булса бер уйнаучының аяк арасыннан тәгәрәтеп җибәрергә тырыша. Туп үзенә таба тәгәрәп килгән бала, аякларын тиз генә янәшә куеп, аны аяклары арасыннан чыгармаска тиеш. Тупны аяк арасыннан үткәргән бала түгәрәктән
бер адым артка китә. 2–3 бала тупны аяклары арасыннан
җибәргәч, уен тәмамланган санала.

***Бергәләп өйрәник***



# ***Кеше һәм предметлар дөньясы***

## ***Әти-әниләр өчен методик ярдәмлек***

***(4-5 яшь)***

## Мәкальләр

* Китап — белем чишмәсе.
* Китап галим — телсез мөгаллим.
* Китапның белмәгәне юк.
* Китапсыз өй — ишәк абзары.
* Үзеңнең надан икәнеңне беләсең килсә, күп китап укы.

## Табышмаклар

* Кышын да, җәен дә
бертөсле.
(Чыршы, нарат)
* Ап-ак күлмәген кигән,
Күлмәгенә тап тигән.
(Каен)
* Озын, яшел — түтәлдә,
Сары, тозлы — кисмәктә.
(Кыяр)
* Үсеп утыра бер чүлмәк,
Өстенә кигән йөз күлмәк.
(Кәбестә)
* Нинди агач җилсез шаулый? (Усак)
* Алсу битле кыз үсте,
Кызарып, җиргә төште. (Алма)
* Җир астында җиз бүкән,
Һәр көн ашыйсың, иркәм. (Бәрәңге)
* Туп түгел — түгәрәк,
Күсе түгел — койрыклы. (Чөгендер)
* Кызыл төймә таптым,
Авызыма каптым.
(Җиләк)

## Кәгазь

Без укый торган китаплар,
без яза торган дәфтәрләр,
без карый торган альбомнар
башта — агач булганнар.
Яфрак ярып, җилдә шаулап,
Җирдә басып торганнар.

Аннан аларны екканнар,
чапканнар да кискәннәр...
Машиналардан үткәреп,
юка кәгазь иткәннәр.
Алдымда — чиста ак кәгазь,
Нинди агачтан икән Каеннанмы, нараттанмы,
әллә усактан микән?
Аның урынына яңаны
кемдер утырткан микән?..
...Уйлап тордым да ясадым
кәгазьгә бер имәнне.
Ясадым мин имәннең
шәбен — менә дигәнне!
Очы күккә тигәнне,
мәңге үсеп торырлыкны.
— Кош оя корырлыкны.
Күргән кеше шатлансын

*Хәрәкәтле уеннар*

## Туп кайда?

Санамыш ярдәмендә уенны алып баручы сайлана. Балалар түгәрәккә басалар. Алып баручы уртада басып тора. Уйнаучылар, алып баручыга сизелмәслек итеп, арттан туп бирешәләр. Әгәр алып баручы тупның кемдә икәнен сизсә, аның янына килеп: «Кулларыңны күрсәт», – ди. Әлеге бала, учларын өскә каратып, кулларын югары күтәрә. Әгәр аның кулында туп булса (яки ул тупны төшереп җибәрсә), уен тәмам була. Әгәр туп анда булмаса, ул кулларын яңадан артка куя, һәм уен дәвам итә. Туп белән 2–3 бала тотылгач, алып баручы алышына.